**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 23.05.2022** **№ 506**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбъяз авыл җирлегенең генераль планы проектын килештерү буенча Килештерү комиссиясен төзү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 25 статьясы нигезендә, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Дөбъяз авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты буенча каршылыкларны җайга салу буенча килештерү комиссиясен төзергә.

2. Кушымтада бирелгән түбәндәгеләрне расларга:

Килешү комиссиясе эшчәнлеге тәртибен. (1 нче кушымта)

Килешү комиссиясенең составын. (2 нче кушымта).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы А.М. Хөснетдиновка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ф. Хисамутдинов

1 нче кушымта
РАСЛАНДЫ
Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының
23.05.2022 №506
номерлы карары белән

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы «Дөбъяз авыл җирдеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты буенча каршылыкларны җайга салу буенча килештерү комиссиясе эшчәнлеге тәртибе**

1. Килештерү комиссиясе үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 25 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Региональ үсеш министрлыгының «Муниципаль берәмлекләрне территориаль планлаштыру документлары проектларын, территориаль планлаштыру документлары проектларын килештергәндә, килештерү комиссиясе составын һәм эш тәртибен раслау турында» 2016 елның 21 июлендәге 460 номерлы боерыгына, Биектау муниципаль районы Уставына таяна.

2. Килештерү комиссиясе үз эшчәнлеген дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка кызыксынган затлар белән үзара хезмәттәшлектә гамәлгә ашыра.

3. Килештерү комиссиясенең максималь эшләү срогы аны төзегән көннән алып өч айдан арта алмый.

4. Килештерү комиссиясен төзү датасы итеп Биектау муниципаль районы башкарма комитетының Килештерү комиссиясенең эшчәнлек тәртибен һәм составын раслау турындагы карарын Биектау муниципаль районының рәсми порталында рәсми бастырып чыгару датасын санарга.

5. Килештерү комиссиясе утырышын Килештерү комиссиясе рәисе оештыра һәм алып бара, ә ул булмаганда - рәис урынбасары.

6. Килештерү комиссиясе утырышларында комиссия әгъзалары катнаша, ә кирәк булганда, Килештерү комиссиясе утырышларында гамәлдәге законнар нигезендә башка органнар вәкилләре катнашырга мөмкин.

7. Килештерү комиссиясе утырышы, әгәр анда исемлек составының кимендә 50%ы катнашса, хокуклы дип санала.

8. Килештерү комиссиясе утырышы беркетмәсе рәис һәм секретарь тарафыннан имзалана.

9. Килештерү комиссиясе кабул иткән карарга каршы тавыш биргән Килештерү комиссиясе әгъзалары беркетмәгә кушымта итеп биреләчәк һәм аның аерылгысыз өлеше булып торачак аерым фикерне рәсмиләштерергә мөмкин.

10. Килештерү комиссиясе карары утырышта катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, Килештерү комиссиясе рәисенең тавышы хәлиткеч була.

11. Килештерү комиссиясенең эш нәтиҗәләре Килештерү комиссиясе утырышы беркетмәсендә чагыла.

12. Үз эшенең нәтиҗәләре буенча Килештерү комиссиясе түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

12.1. Территориаль планлаштыру документы проектын әлеге проект белән килешмәү өчен нигез булып торган барлык искәрмәләрне исәпкә ала торган үзгәрешләр кертеп килештерергә.

12.2. Территориаль планлаштыру документы проектын, баш тарту турында карар кабул итү өчен нигез булып торган сәбәпләрне күрсәтеп, килештерүдән баш тартырга.

13. Килештерү комиссиясе үзенең эш йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә җибәрә:

13.1 Тәртипнең 12 пунктындагы 12.1 пунктчасында күрсәтелгән карар кабул ителгәндә, аңа кертелгән үзгәрешләр белән территориаль планлаштыру документы проекты, Килештерү комиссиясе утырышы беркетмәсе, килештерелмәгән мәсьәләләр буенча текст формасында һәм карталар рәвешендәге материаллар белән бергә.

13.2 Тәртипнең 12 пунктындагы 12.2 пунктчасында күрсәтелгән карар кабул ителгәндә, территориаль планлаштыру документының килештерелмәгән проекты, территориаль планлаштыру документы проекты белән килешмәү турында бәяләмә, Килештерү комиссиясе утырышы беркетмәсе, шулай ук килештерелмәгән мәсьәләләр буенча текст формасында һәм карталар рәвешендәге материаллар.

12 пунктның 12.2 пунктчасында күрсәтелгән документлар һәм материаллар үз эченә алырга мөмкин:

Килештерелмәгән мәсьәләләр буенча материалларны территориаль планлаштыру документы проектыннан төшереп калдыру турындагы тәкъдимнәрне (шул исәптән, килештерү вакытына кадәр килештерелмәгән мәсьәләләрне теркәү максатларында тиешле картада аларны чагылдыру юлы белән);

Территориаль планлаштыру документын тиешле үзгәрешләрне мондый территориаль планлаштыру документына кертү тәкъдимнәрен әзерләү юлы белән раслаганнан соң, Тәртипнең 12 пунктындагы 12.1 пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләләрне килештерү планы.

14. Килештерү комиссиясе тапшырган беркетмәләр һәм материаллар нигезендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының килештерелгән яки аерым өлешләрендә килештерелмәгән территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проектын раслау яисә раслаудан баш тарту һәм аны эшләп бетерү өчен җибәрә.

15. Килештерү комиссиясе адресына язма рәвештә керә торган гаризаларга һәм сорауларга җаваплар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән срокларда бирелә.

16. Килештерү комиссиясе карарларына карата Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

2 нче кушымта
РАСЛАНДЫ
Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 23.05.2022 № 506
номерлы карары белән

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы «Дөбъяз авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планы проекты буенча каршылыкларны җайга салу буенча килештерү комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Хәкимуллин Р.Ф. | Комиссия рәисе, башкарма комитет җитәкчесенең төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча урынбасары |
| Галиуллин Р.Ш. | Комиссия рәисе урынбасары, Дөбъяз авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе |
| Әхмәтҗанов А.Х. | Комиссия секретаре, төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлегенең баш белгече |
| | Комиссия әгъзалары |
| Таҗиев И.И. | Район Советының юридик бүлеге башлыгы |
| Хөснетдинов А.М. | Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы |
| Вәкил | Төзелеш, архитектура һәм ТКХ министрлыгы (килешү буенча) |